ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә региональ инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда салым салуның аерым мәсьәләләрен җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә региональ инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда салым салуның аерым мәсьәләләрен җайга салу турында» 2022 елның 21 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 24 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда «20 процент» сүзләрен «25 процент (2024 елга кадәрге, шул елны кертеп, салым чорлары өчен 20 процент)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда:
а) 1 өлештә «, әлеге статьяның 2 өлешендә каралган очрактан тыш,» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 25 декабрь
№ 106-ТРЗ